| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

24.05.2023 Казан ш. № 1365-р

Газ бүлү челтәренең (газүткәргеч) саклык чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 30.12.2013 № 4083-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” 2015 елның 15 июлендәге № 218-ФЗ Федераль Законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУның хатын (№ 01А-04/1202, 18.05.2023) истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында" 30.12.2013 № 4083-р Карары (алга таба - № 4083-р Карар) белән урнаштырылган 4538 м. озынлыктагы, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендәге, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянка т.п. территориясенә урнаштырылган инвентарь номеры 18427 булган газ бүлү газүткәргеченең 261,1 м.на демонтаж ясау һәм 16:21:000000:1169, 16:21:040601:12 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә 29,6 м газ бүлгеч газүткәргечен монтажлау сәбәпле, саклык зонасын «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезләндә урнаштырып үзгәрешләр кертергә.

2. Инвентарь номеры 18427 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасынданы белешмәләргә, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән газүткәргечнең характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, № 4083-р Карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 28.12.2018 № 4633-р, 05.11.2020 № 3401-р, 07.04.2021 № 1121-р, 24.03.2023 № 779-р, 29.03.2023 № 844-р Карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Кайбыч муниципаль районы территориясендәге 306,77 км. озынлыктагы, гомуми мәйданы 1,4935 кв.км.лы 6 нчы кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү газүткәргечен, «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «РКЦ «Земля» АҖ, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ, «Гео-Инженеринг» ҖЧҖ, «БАРС» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты

объектларының саклау зонасы картасында (планы) булган белешмәләр нигезендә;

6 нчы кушымтада:

инвентарь номеры 18427 булган газүткәргечкә туры килгән юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>140</td><td>Кайбыч</td><td>18427</td><td rowspan="2">4306,5</td><td>Г.З.1/18427</td><td>Олы Подберезье</td><td>С № 92 Ульянково юл чатында</td><td>16-16-10/2002-58.1</td></tr>
<tr><td>141</td><td>Кайбыч</td><td>18427</td><td>ГРП1 26165/18427</td><td>Ульянково</td><td>С № 93 Ульянково юл чатында</td><td>16-16-10/2002-58.1</td></tr>
</table>

4. Әлеге карарның үтәлеген контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**